ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2024 ел Баулы шәһәре №138

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының “Физик зат алдындагы акчалата үтәлергә тиешле гавами йөкләмәләрне үтәү буенча “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы вәкаләтләрен муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашыру һәм аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында” 2010 елның 3 ноябрендәге, 197 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының “Физик зат алдындагы акчалата үтәлергә тиешле гавами йөкләмәләрне үтәү буенча “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы вәкаләтләрен муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашыру һәм аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында” 2010 елның 3 ноябрендәге, 197 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

карарның атамасында һәм 1 пунктында “учреждение” сүзеннән соң “һәм автоном учреждение" сүзләре белән тулыландырырга”;

физик зат алдындагы акчалата үтәлергә тиешле гавами йөкләмәләрне үтәү һәм аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү буенча “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы вәкаләтләрен муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашыру Кагыйдәләрендә:

карарның атамасында “учреждениесе” сүзеннән соң “һәм автоном учреждениесе" сүзләре белән тулыландырырга”;

1 пунктта "бюджет учреждениесе" сүзеннән соң "һәм автоном учреждениесе" сүзләрен өстәргә»;

2 пунктта «индексация күләмендә яисә билгеләнгән тәртибе булган» сүзләрен «индексация күләмендә һәм (яисә) билгеләнгән тәртибе булган " сүзләренә алмаштырырга»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Учреждение бюджет акчаларын алучыларның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше турында еллык, квартал һәм айлык хисапны төзү һәм тапшыру өчен Россия Федерациясе Финанс Министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бюджет акчаларын баш урнаштыручыга гавами йөкләмәләрнең үтәлеше турында хисап тапшыра.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) Һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров